УДК 811.512.145'375

***И.Ф. Миргалимов***

## ТАТАР ТЕЛЕНДӘ *ПРОСТРАНСТВО* КОНЦЕПТЫНЫҢ ВЕРБАЛЬЛӘШҮ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Каждый народ имеет свой метод познания Пространства и комплекса представлений о его устройстве и космогонии. Многие народы приходят к пониманию данной категории в связи с первобытными представлениями о природных явлениях. В статье рассматриваются средства вербализации концепта *пространство* в татарском языке.

**Ключевые слова:** татарская языковая картина мира, концепт, *пространство, место, ориентация, центр, вселенная.*

Тел һәм әдәбият белеме өлкәсендә урын-ара мәгънәсен яки «пространство» концептын белдерә торган репрезентлар күп түгел. Иң элек, «пространство» терминының сүзлекләрдә теркәлгән мәгънәләре белән танышып үтик.

*Пространство* лексик берәмлеге үзенең этимологиясе белән рус теленә барып тоташа. Русча-татарча тәрҗемә сүзлегендә аның түбәндәге мәгънәләре теркәлгән:

1) киңлек; воздушное пространство – һава киңлекләре; 2) *филос*. пространство; пространство и время – пространство һәм вакыт. 3) (*место; промежуток*) бушлык; аралык, буш урын; безвоздушное пространство – бушлык, вакуум; занимать две трети пространства – урынның өчтән ике өлешен алып тору; свободное пространство между окном и дверью – тәрәзә белән ишек арасындагы буш урын; 4) (*земельная площадь*) мәйдан [Русско-татарский словарь, с. 497].

«Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *пространство* лексемасы фәлсәфә фәне кысаларында аңлатыла: Пространство *филос*. Материя яшәешенең озынлык һәм күләм белән характерлана торган гомуми төп объектив формаларының берсе [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, б. 430].

М.И. Мәхмүтов, К.З. Хәмзин, Г.Ш. Сәйфуллиннар төзегән «Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге»ндә пространство *фәза* (фәзаэ) алынма сүзе белән атала. Ул *күктәге* (һавадагы) *бушлык; ачык урын, ачыклык* дип тәрҗемә ителә [Мәхмүтов, Хәмзин, Сәйфуллин, б. 632].

Урын-ара мөнәсәбәтләре борынгылар тарафыннан дөнья шәкеленең иң әһәмиятле атрибутларыннан саналган. Борынгы төркиләрдә пространство – «бар җир» төшенчәсе «кояшның беренче нурларыннан алып, көнбатыш чикләренә кадәр булган» киңлекне аңлата. Алар фикеренчә, *пространство* дүртпочмаклык формасында. Татарларның бабалары аңында ул реаль яки мифологик юллар белән үзләштерелгән һәм хаоска каршы куел-

ган тәртипкә салынган дөньяны аңлаткан.

Борынгы төркиләр һәм шул исәптән болгарлар карашынча, хаос, ягъни буталчык, тәртипсез башлангычны чагылдыручы иксез-чиксез су өермәсеннән дөнья, галәм барлыкка килә, хаос тәртипкә керә, *пространство* – Җир, Кояш, Ай ярала.

Халык дөньяны ничек күрсә, аның аңында шундый дөнья төзелеше чагылыш таба. Ул яшәешне шул рәвешле күреп аңлый һәм бу дөньяның милли образын тәшкил итә.

Соңгы вакытта тюркологиядә дөньяны тел чаралары ярдәмендә сурәтләү мәсьәләләрен өйрәнүгә игътибар арта башлады. 2006 елда Ә.Р. Тенишев редакциясендә төрки халыкларның дөнья картинасы модельләренә багышланган «Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Лексика» исемле китап басылып чыкты. Әлеге хезмәттә төрки халыкларның дөнья моделе 3 катлы пространствога бүлеп тасвирлана: өске катны күк (небо), урта катны җир (земля), аскы катны җир асты (подземелье) тәшкил итә [Сравнительно-историческая грамматика..., с. 326].

Татар лингвокультурасында дөнья картинасын өйрәнү башланып кына килә дисәк тә, ялгыш булмас. Татарларда дөнья моделе, төрки халыклардагы кебек, 3 катлы булып күзаллана: күк (небо) – өске дөнья, җир (земля) – урта дөнья, җир асты (подземелье) – аскы дөнья. Башкорт тел белгече З.М. Раемгужинаның «Языковая картина мира в башкирской фразеологии» дигән фәнни хезмәтендә ул тагын да конкретлаштырыла төшә [Раемгужина, с. 11]. Өске дөнья – күк, һава. Анда кояш, ай, йолдызлар, Алла (Ходай, Тәңре). Урта дөнья – җир, җир-су, кешеләрнең һ.б. җан ияләренең тереклек урыны. Аскы дөнья серле кала. Ул кешеләрне, хайваннарны күмү, җирләү, кара көчләрнең яши торган җирләре булып санала.

Ф. Урманченың «Татар мифологиясе» энциклопедик сүзлегендә дөньяның космогоник мифларда чагылышы аңлатыла. Борынгы заманда кешеләр *Җирне*, хәзерге шикелле шар рәвешендә түгел, ә бәлки тигез, яссы урын буларак кабул иткәннәр. Җиһанның (Галәм), шул исәптән Җирнең дә, гомуми төзелешен безнең ерак бабаларыбыз түбәндәгечә күз алдына китергәннәр: тигез, яссы җир үгез мөгезендә тора. Бу үгез үзе зур балыкның мыегына беркетелгән. Балык чиксез-кырыйсыз суда йөзеп йөри. Җирне төрле яктан чорнап алган су мәңгелек караңгылыкка күмелгән. Ягъни, борынгы чор дөнья мифологиясендә тасвирланган җиһандагы *тәүге тәртипсезлек* («первобытный хаос») төшенчәсе билгеле бер дәрәҗәдә татарларның милли мифологиясендә дә чагылыш таба. Җир Җиһанның (Галәм) үзәге буларак карала. Димәк, Күк патшалыгындагы Ай, Кояш, йолдызлар, табигатьнең җанлы көчләре буларак, Җир мәнфәгатьләре белән генә яшиләр.

Иң борынгы карашлар буенча Җирнең барлыкка килүе бик җиңел хәл ителә. Безнең

көннәргә кадәр сакланган легендада бу хакта түбәндәгеләр сөйләнә: «Элекке заманнарда дөнья тоташ судан гына торган. Кешеләр әле булмаган. Суда балыклар һәм су кошлары гына яшәгәннәр. Шунда бер үрдәк, су төбенә чумып, борыны белән бер кисәк балчык алып чыккан. Ул зурайган һәм шуннан җир хасил булган, ди». Бу легендага карата Х. Гыйләҗетдинов шундый искәрмә бирә: «Болгар чорына караган археологик материаллар арасында авызына шар капкан үрдәк сурәтле бизәнү әйберләре очравы бу мотивның борынгы болгарлардан таралган булуы турында сөйли». Борынгы болгар мифологиясе буенча, Җир, Кояш, Ай бер үрдәк салган күкәйдән яралган дип тә уйланылган [Урманче, б. 11–12].

Галәм өч каттан тора: Күк дөньясы, без яшәгән Җир һәм Җир яки Су асты дөньясы. Күк дөньясы Ай, Кояш, Кошлар патшалыгы белән бәйләнгән булса, Җир өсте – кешеләр яши торган гадәти дөнья. Ә инде Җир асты яки Су асты патшалыклары Үлеләр дөньясы санала. Анда бу фани дөньядан киткән кешеләр, аларның рухлары, Аждаһа, Дию, Елан, гыйфритлар гомер итә. Соңгылары кешелек дөньясына зыян салып торалар.

Борынгы төркиләр фикеренчә, *вертикаль дөнья* өч өлештән тора:

1) Югары дөнья, Күк, Тәңре дөньясы;

2) Урта дөнья, җир өсте, «Удук Йир-Суб» – «изге Җир-Су». Ул «Удук Йир-Суб» алласы белән идарә ителә. Борынгы төркиләр аңында Йир-Суб бербөтенлекне, туган ил мәгънәсен белдергән;

3) Җир асты, үлеләр дөньясы. Аның белән Эрклиг исемле алла идарә итә.

Бу дөньялар арасында күченеп йөрергә мөмкин. Моның өчен изге биек таулар, биек ялгыз агачлар, кошлар, канатлы атлар хезмәт итә. Алар Юл тәңресе карамагында.

Болгарлар, борынгы төркиләр кебек үк, *вертикаль дөнья* өч өлештән: Җир, Күк, Җир асты дөньяларыннан тора дип уйлаганнар [Дәүләтшин, б. 200].

Димәк, Җиһан без яшәгән Җир өсте дөньясы белән генә чикләнми: анда башка – икенче, хәтта өченче дөньялар да бар икән. Шулай булгач, аларда гомер итүче затлар да төрле булырга тиеш. Җирдә булмаган һәм һич тә була алмаган күренешләрнең, затларның барысы да Җир асты яки Су асты патшалыкларында урын ала. Гомумән алганда, бу патшалыклар, бу дөньялар билгеле бер дәрәҗәдә Җир өсте патшалыгының киресен гәүдәләндерәләр [Урманче, б. 20–21].

Нәтиҗә ясап әйтсәк, пространство яки урын-ара ул, иң беренче чиратта, безне чолгап алган дөнья, галәм, яшәеш, барлык, тереклек. Әлбәттә, Күк, Җир асты дөньяларын да кире кагып булмый. Тик аларның икесе дә кешеләрнең ышануларына бәйле. Шулай ук бу мәсьәләдә дин һәм дин кануннары да зур әһәмияткә ия. Кайберәүләр Җир астын «түбән мифологик затлар» яши торган урын дип түгел, бары тик байлык, файдалы казылма-

лар тупланган, яшеренгән хәзинә дип кенә уйлыйлар. Күк дөньясын да аерым илаһи затлар яши торган урын дип санаучылар бар. Ә кешеләр яши торган Җир өсте дөньясы һәркем өчен дә билгеле, бар дип санала һәм кабул ителә.

Ягъни, *пространство* яки *урын-ара* ул – киңлек; җир, урын; аралык, бушлык; мәйдан; материя яшәешенең төп объектив формаларының берсе; ачык урын, ачыклык; фәлсәфи төшенчә; Җир; Күк; Җир асты һ.б.

**Әдәбият**

*Дәүләтшин Г.М.* Төрки-татар рухи мәдәнияте тарихы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. 429 б.

*Мәхмүтов М.И., Хәмзин К.З., Сәйфуллин Г.Ш.* Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге. II том. Казан: Иман, 1993. – 853 б.

*Раемгужина З.М.* Языковая картина мира в башкирской фразеологии.: дис. ... канд. филол. наук. Уфа, 2000. 137 с.

Русско-татарский словарь. М.: Русский язык, 1984. 730 с.

Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Лексика / под ред. Э.Р. Тенишева. М.: Наука, 2001. 986 с.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Казан: Матбугат йорты. 2005. 849 б.

*Урманче Ф.И.* Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек. Өч томда. II т. Казан: Мәгариф, 2009. 343 б.

***Миргалимов Илдар Флүс улы,***
*Республика Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе урынбасары*
*E-mail: ildarfm.kazan@gmail.com*